ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 626-201/кс-2022

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2023 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Татэнерго» АҖ) бирелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән

расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2022 ел өчен тарифлар билгеләү хакында» 19.01.2022 № 6-1/кс-2022 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 626-201/кс-2022
карарына кушымта

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» АҖ бирелә торган кайнар суга 2023 елга тарифлар

| № | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Җылылык саклау компонен-ты, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Егәрлек өчен ставка, аена мең сум/1 Гкал/сәг. | Җылылык энергиясе өчен ставка, сум/Гкал |
| 1 | "Татэнерго" АҖ* | | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре | | | | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)** | 2023 ел | 28,12 | 2367,97 | - | - |
| 1.1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 2023 ел | 23,43 | 1973,31 | - | - |

<*> Җылылык китерү матдәсенә компонентлар исәбенә кабул ителә торган җылылык китерү матдәсенә «Татэнерго» АҖ өчен тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 17.12.2018 № 5-89/тэ карары белән билгеләнгән.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге